**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ӘЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

«18» март 2026 ел № 17

# КАРАР

**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

«Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Указының 4 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

1.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Советының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне бирү тәртибен раслау хакында» 2017 елның 26 сентябрендәге 50 номерлы карар.

1.2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 28 маендагы 22 номерлы Карарының 4 пункты.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга. https://pravo.tatarstan.ru/ һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ һәм җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы
Иске Әлмәт авыл җирлеге Советы Рәисе Р.Г. Хисамов